ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

27.02.2023 г. Заинск № 134

**Торак бинаны карап тоткан өчен түләү күләмен үзгәртүнең чик индексын билгеләү турында**

Россия Федерациясе Торак кодексының 158 статьясы 4 өлеше, "Торак урын милекчеләре өчен торак урынны карап тоткан өчен түләү күләмен билгеләү буенча күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән, торак урынны карап тоткан өчен түләү күләмен билгеләү турында, шулай ук мондый түләүнең иң чик индексларын билгеләү тәртибен билгеләү буенча методик тәкъдимнәрне раслау турында" 2018 елның 06 апрелендәге 213/пр номерлы Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы боерыгы нигезендә, Зәй муниципаль районы Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. 2023 елга күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән торак урыннар милекчеләре өчен торак урынны карап тоткан өчен түләү күләмен үзгәртүнең чик индексын 6% күләмендә билгеләргә.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга, массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
4. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Э.Э. Галеев**

А.Н. Симашева
8(85558) 3 13 37